ГЛАВА АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.08.2021 п.г.т. Аксубаево №54

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Трудолюбово авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Трудолюбово авыл җирлегенең генераль планы проектын караганнан соң, кешенең уңайлы тормыш шартларына хокукларын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003, №131-ФЗ Федераль законның 28 статьясына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 20 статьясына таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Трудолюбово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча килә торган тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

   – эшче төркем рәисе, Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Исламов Илдар Ирек улы;

– эшче төркем секретаре, Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе Тимкина Оксана Александровна

Эшче төркем әгъзалары:

- Трудолюбово авыл җирлеге Советы депутаты-Сафиуллин Рәмис Виль улы

- Трудолюбово авыл җирлеге Советы депутаты -Тарасова Светлана Александровна

- Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге җитәкчесе Емельянов Андрей Аркадьевич

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Трудолюбово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (1нче кушымта).

3. «Трудолюбово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы

проектында булган материаллар белән Трудолюбово авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында түбәндәге адрес буенча танышырга мөмкин: Трудолюбово авылы, Совет ур., 6, эш көннәрендә 8:00 дән 16:00 гә кадәр һәм Аксубай муниципаль районы сайтында: http://Aksubaevo.tatarstan.ru.
Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге, Аксубай штп, Ленин урамы,8 нче йорт адресы буенча урнашкан, Трудолюбово авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җыю урыны итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Трудолюбово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлауларны __. 08.2021 ел, 10.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Трудолюбово авылы, Елга аръягы урамы, 5 (клуб бинасы).

5. Эшче төркем тарафыннан килгән тәкъдимнәрне гомумиләштерергә һәм аларны Аксубай муниципаль районы Советы каравына кертергә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Трудолюбово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://Aksubaevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И. И. Исламовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы башлыгы: К.К.Гыйлманов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ р06-633/13 ИНН 1603004737 КПП160301001 ОГРН1061665009960

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
«Трудолюбово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Генераль планы проекты буенча
гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу
һәм аның турында фикер алышуларда катнашу
ТӘРТИБЕ

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Трудолюбово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча тәкъдимнәр Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча кертелә: Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Аксубай штп, Ленин ур., 8, кушымта итеп бирелә торган үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язма рәвештә:

| № т/б | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмәләр тексты | Төзәтмәне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмә авторы (ФИА, адрес, эш, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр, карар кабул ителгән көннән алып, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Трудолюбово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бер ай эчендә кабул ителә.

Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар ТР, Аксубай районы, Аксубай штп, Ленин урамы, 8 йорт адресы буенча Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлегенә шәхсән тапшырыла.

Гаризалар (сорау язулары) эш көннәрендә 8:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советына Аксубай муниципаль районының ачык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә карау өчен тапшырыла.